
АБДУЛЛА АЛИШ

# Койрыклар





УДК 821.512.145-93
ББК 82.84(2=632.3)
А 51

ISBN 978-5-9907052-4-1

АБДУЛЛА АЛИШ

# Койрыклар

Балалар өчен яраклаштырылган басма

Казань
2016

Борын-борын заманда хайваннарның, ерткыч җанварларның койрыклары бөтенләй булмаган. Кешнәүче ат та, мөгрәүче сыер да койрыгы белән чебен кумаган. Шаян тиен дә, чикләвекләр ашап, ботактан ботакка сикереп уйнамаган.





Көннәрдән беркөнне тылсымлы карт имәндә койрыклар үскән.

Бервакыт аксакал җәнлекләр койрык алу турында киңәшергә җыелганнар. Ак түшле саесканнарны чакырганнар, аларга да зур йомыш тапшырганнар:





«Ак түшле саесканнар, очыгыз, еракларга җитегез: биек-биек тауларга, шаулап торган урманнарга, ямь-яшел болыннарга, җырлап аккан суларга безнең сүзне илтегез. Барлык хайваннарны, җәнлек-җанварларны чакырыгыз: үткәргәч караңгы төнне, томан беткәч тә, кояш күтәрелгәч тә, карт имән янында өләшәчәкләр, диегез, койрык, менә сезгә шул безнең боерык».

Саесканнар төрлесе төрле якка очканнар, үзләре белән зур-зур быргыларны кычкыртып барганнар.





«Әй, сез, куе урманнарда, киң кырларда, яшел болыннарда, диңгез-океаннарда яшәүче ерткычлар. Томан беткәч тә, кояш күтәрелгәч тә, бөтенегез дә карт имән янына барыгыз, койрык өләшәчәкләр, килеп алыгыз», – дигәннәр.





Үткәргәч караңгы төнне, шул билгеләнгән беркөнне ерткычлар койрык алырга карт имән янына барырга юлга чыкканнар: кайсы үрмәләгән, кайсы йөгергән, кайсы чапкан.

Бары тик куркак куян гына үз өеннән ерак китәргә курыккан.

Зур колак Куян оясында озак утырмаган, дөп тә дөп басып килгән аяк тавышын ишеткән, карамыйча куркуына, йөгереп тышка чыккан. Агач куышына кереп утырган да ерактан килүчене карарга тотынган.





«Кулына тотып таяк, киләдер теге кәкре аяк», – дип уйлаган Куян һәм, чыннан да, шулай булып чыккан.

Куян килүчегә сүз кушкан:

– Аю бабай, башкалардан артка калмыйсыңдыр, үзеңә койрык сайлыйсыңдыр, шунда миңа да нинди генә булса да бер койрык алып кайта алмассыңмы икән? – дигән.

– Әгәр дә онытмасам, алып кайтырмын, авыр эшмени ул, – дигән Аю.





Аю киткәч: «Ярарын ярар, шулай да аңа ышанып булмый, – дип уйлаган Куян. – Аю бабай инде картайган, зиһене дә таралган. Онытыр вәгъдәсен, аннан табар хәйләсен, тагы кемнән дә булса башка берәүдән үтенергә кирәк».

Тагы тып-тып атлаган тавыш ишетелгән, вак чыбыкларны чыжылдатып, кем соң ул йөгерә? Ә, Бүре килә.

– Бүре абый, карт имән янына барасыңдыр, үзеңә койрык аласыңдыр, шунда миңа да нинди дә булса берәр койрык алып кайта алмассыңмы икән? – дигән Куян.





– Барысына да җитәрлек булса, берәрсе артып та калса, алып кайтырмын, – дип, Бүре китеп барган.

– Юкка әрәм иттем моңа сүз, Бүре бит ул туймас күз, сайлап бетерерләр, берәү дә калмас, артып калса да, ул алмас, миңа бирмәс, бозар вәгъдәсен, табар хәйләсен. Кемне дә булса тугрыракны, бу эш өчен хубракны табарга кирәк, – дигән Куян.

Тагы кемдер дөп тә дөп итеп басып килә, ди. Үлән әз генә селкенә, ди. Ул Төлке булып чыккан.

– Бу эш түгел көлке, апакаем Төлке, үзем бара алмадым, ахры, инде койрыксыз калдым. Карт имәнгә барасыңдыр, үзеңә койрык аласыңдыр. Сиңа бу зур үтенечем, боерык дип уйлама, алып кайтмассыңмы икән миңа бер койрык.





– Ярый, ярый, һич хафаланма, берәүгә дә зарланма. Куян дустым сорады, диярмен, койрыкның менә дигәнен алып кайтып бүләк итәрмен. Туның белән бертөсле булыр, әллә кайдан ук күренеп торыр.

Төлке барысыннан да соң юлга чыкса да, Куян янында шактый тукталып торса да, иң туры юллар табып, бар көченә чабып, карт имән янына иң алдан барып җитә.

Койрыклар белән карт имәннең ботаклары тулган, һәр ботак саен бер койрык асылынган: йонлач озыннары да, йонсыз ялангачлары да, җеп шикеллеләре дә, алтын йон белән капланганнары да, кара һәм аклары да, көкреләре дә, турылары да – бар да бар.





Җыелган ерткычлар, аларны күреп, хәйран калганнар, башларын кыңгыр салганнар. Көтмичә бернинди боерыкны, беренче булып Төлке сайлый койрыкны: «Миңа менә шушысын, мамыклысын, йонлысын», – ди. Башкалар йоклап кала, ә ул үзенә менә дигән бер койрыкны сайлап ала. Төлке әйләнә дә тулгана, койрыгы да бергә болгана.

Сыерның да койрыгы яхшы, Бүренең дә начар түгел. Тиен дә койрыктан уңган, сикерсә, пружинадай булган, йокласа – юрган.





Аю юлда умарталыкка очраган, туйганчы бал ашаган, шуңа күрә койрык алырга да соңга калган, шулай да бернәрсә тапкан, тире кисәген койрык итеп таккан.






Куян койрык алып кайтучыларны көткән, оясында ятып та аптырап беткән, ахыр чиктә түзмәгән, кайсын булса да берсен очратырмын диеп, юлга чыгып киткән.

Тау битендә Төлке күренгән, Куян аңа каршы йөгергән.

Куян чакырганны көтмәгән-нитмәгән, аның каршысына барып баскан:

– Апакаем, багалмакаем, миңа дигән койрыкны биреп калдыр, мине шатландыр, – дигән.





– Син генә идең минем башымда, әллә нинди җайсызлыклар чыкты каршыма. Син менә күз сал әле, кызыгып кал әле: йомшак кына, мамык кына, үземә менә дигәнне эләктердем, хәер, шуның аркасында күп мал бетердем, – дигән Төлке.

Шул сүзләрне әйтеп, күз уйнатып, Куян борыны янында койрыгын болгап, Төлке көлеп торган.

Күп тә үтмәгән, Бүре күренгән, Куян аңа каршы йөгергән.

– Бүре абый, Бүре абый, миңа дигән, менә дигән койрыкны бир, абый, – дигән.





– Кая әле сиңа дигән койрык, үземә дә көчкә генә берне эләктердем, – дигән Бүре.

Бүре шулай дигән дә киткән, ә Куян Аюны өзелеп көткән.

Әнә еракта алпан-тилпән кайтучы Аю күренгән. Куян, шатланып, әйтерсең канатланып, Аюга каршы йөгергән.

– Аю бабай, онытмадыңмы? Менә дигәнен алып кайттыңмы? – дигән.





– Кит әле моннан, ялкау Куян! Үзең бармагач, армагач-талмагач, кыршылмагач, сугышмагач, тик утырып кына койрыклы булып буламы соң, юләр. Мин менә йөгерә-йөгерә барып та, үлә язганчы арып та, менә шушындый кыска койрык кына эләктерә алдым, – дигән Аю Куянга.

Аю мескен Куянны тиргәгән дә киткән.

Куян, койрык көтеп, бик зарыккан булган. Мескеннең күңеле тулган. «Менә кирәк булса, туганнар барысы да мине онытканнар», – дип, елап ук җибәргән.





Шулай күңелсезләнеп утырганда, тирә-ягын күз яше белән тутырганда, ишеткән куян: «Вау да вау, мырау да мырау». Борылып карый, карый да: «Менә монысы ярый». Эт белән мәче ду килеп сугышалар икән.





Эт: «Минем койрык иң яхшысы!» – дигән. Мәче аңа аркылы төшкән: «Минеке ише дөньяда да юк!» – дигән. Тартышканнар да тартышканнар. Әүмәкләнә торгач, Мәченең койрык очы өзелеп чыккан. Мескенем куркуыннан агач башына ук менеп киткән. Өзелгән койрыкны җил, тәгәрәтеп, Куян оясына илткән. Ә Куян аны үзенә койрык иткән. Шул көннән башлап, Мәче белән Эт арасындагы бу ызгыш мәңгелеккә киткән.

Әкият тә шуның белән беткән.

ТОИ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ

# ХУДОЖЕСТВЕННО-АНИМАЦИОННОЕ ИЗДАНИЕ

**Абдулла Алиш әкияте**
**татар һәм рус телләрендә мультфильм**

**Сказка Абдуллы Алиша**
**на татарском, русском языках**


Руководитель проекта **Азат Ганиев**
Литературные редакторы **Анна Белоброва, Алсу Марданова**
Художественный редактор **Дамир Бариев**
Художники **Алиса Дьяченко, Дарья Митрофанова, Александра Ахтямзанова, Ольга Волкова**
Компьютерная вёрстка **Дмитрия Гиацинтова**
Главный режиссёр **Сергей Киатров**
Технический директор **Марат Башаров**



© Татарское Детское Издательство


www.tdpress.ru

Отпечатано с готового оригинал-макета
Татарского Детского Издательства
в типографии ООО ПО «Промполиграф»
Печать офсетная, тираж 5000 экз.
Заказ №



Детский книжный магазин
www.tatbook.ru
- УЧЕБНИКИ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА
- ДЕТСКИЕ ПУТЕВОДИТЕЛИ
- ТАТАРСКИЕ СКАЗКИ



ISBN 978-5-9907052-4-1
9 785990 705241